| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.09.2019 Казан шәһәре № 10-3/кс

2019 елга «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына ярашлы рәвештә агынты суларны транспортлауны гамәлгә ашыручы «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен агынты суларны транспортлауга тариф билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф карар үз көченә кергән көннән башлап 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Агынты суларны транспортлауны гамәлгә ашыручы «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.
4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 27.09.2019 № 10-3/кс карарына кушымта

## «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен агынты суларны транспортлауга тариф

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Агынты суларны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|
| | | карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2019 кадәр |
| | Яшел Үзән муниципаль районы | |
| 1 | «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (Көнбатыш Ореховка һәм Дубровка бистәсендәге кулланучылар) | 4,61 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге